**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 декабрь № 1010

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибен раслау турында» 2005 ел, 7 апрель, 161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 28 декабрь, 628 нче; 2006 ел, 22 март, 117 нче; 2006 ел, 5 июль, 341 нче; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 21 март, 98 нче; 2007 ел, 17 декабрь, 726 нчы; 2008 ел, 5 июнь, 373 нче; 2008 ел, 14 ноябрь, 806 нчы; 2008 ел, 18 декабрь, 899 нчы; 2009 ел, 20 апрель, 239 нчы; 2009 ел, 28 декабрь, 897 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1135 нче; 2011 ел, 4 август, 633 нче; 2012 ел, 6 апрель, 279 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 772 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 22 нче; 2013 ел, 26 декабрь, 1062 нче; 2013 ел, 28 декабрь, 1074 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1036 нчы; 2015 ел, 30 ноябрь, 904 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктның «п» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«п) Татарстан Республикасының дәүләт социаль хезмәт күрсәтү системасы хезмәткәрләре;

5 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт социаль хезмәт күрсәтү системасы хезмәткәрләренә билет Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы аша үзәкләштерелгән тәртиптә сатып алына.»;

7 нче пунктта:

беренче абзацта «258 сум» сүзләрен «271 сум» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «427 сум» сүзләрен «448 сум» сүзләренә алмаштырырга;

12 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Транспортта йөрү өчен билетлар һәм балаларга транспортта йөрү өчен билетлар сатудан керем Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының шәхси счетларына күчерелә.

Транспортта йөрүнең шәхсиләштерелгән исәбе булмаган һәм транспорт хезмәтләрен ике һәм аннан күбрәк транспорт оешмасы күрсәткән муниципаль районнарда (шәһәр округларында) транспортта йөрү өчен билетлар һәм балаларга транспортта йөрү өчен билетлар сатудан кергән акча Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан транспорт оешмаларына әлеге муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тапшырган транспорт оешмасы башкарган эшнең өлеше турында мәгълүматлар нигезендә күчерелә».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков